КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 7 август | г.Казань | № 950

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 828 нче; 2012 ел, 7 февраль, 89 нчы; 2012 ел, 10 ноябрь, 977 нче; 2013 ел, 19 март, 191 нче; 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2014 ел, 8 июль, 465 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 846 нчы; 2019 ел, 1 февраль, 61 нче, 2019 ел, 28 август, 721 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1 һәм 6.2 пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карарга теркәлгән кушымтада:

1.13 пунктның өченче графасында «СанПиН 2.4.3259-15» сүзләрен «СП 2.4.3648-20» сүзләренә алмаштырырга;

1.14 пунктның өченче графасында «һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Физкультура-спорт оешмалары

| | | |
|---|---|---|
| Физкультура-спорт оешмалары һәм спорт | физик культура һәм спорт объектларының бер тапкыр | 122»; |

| | | |
|---|---|---|
| резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар | үткәрү мөмкинлеге, 1 000 кешегә | |

4 бүлектә:

«Стационарлар» юлының өченче графасында «СанПиН 2.1.3.2630-10» сүзләрен «СП 2.1.3678-20» сүзләренә алмаштырырга;

«Поликлиникалар, фельдшер-акушерлык пунктлары» юлының өченче графасында «СанПиН 2.1.3.2630-10» сүзләрен «СП 2.1.3678-20» сүзләренә алмаштырырга;

«Ашыгыч медицина ярдәме станцияләре» юлының өченче графасында «СанПиН 2.1.3.2630-10» сүзләрен «СП 2.1.3678-20» сүзләренә алмаштырырга;

5.13 пунктның өченче графасында «СанПиН 2.4.3259-15» сүзләрен «СП 2.4.3648-20» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктның өченче графасында «НПБ 101-95» сүзләрен «СП 380.1325800.2018» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның өченче графасында «СанПиН 2.1.7.1322-03» сүзләрен «СанПиН 2.1.3684-21» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның беренче графасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин